КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 июнь г.Казань № 596

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 ел, 25 октябрь, 523 нче карары белән расланган Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамәгә теркәлә торган документлар составына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 ел, 25 октябрь, 523 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 28 март, 112 нче; 2008 ел, 14 апрель, 232 нче; 2009 ел, 1 июнь, 353 нче; 2010 ел, 20 апрель, 279 нчы; 2010 ел, 19 август, 667 нче; 2011 ел, 29 август, 725 нче; 2012 ел, 13 февраль, 110 нчы; 2012 ел, 25 май, 418 нче; 2013 ел, 26 сентябрь, 684 нче; 2014 ел, 6 август, 572 нче; 2015 ел, 2 апрель, 211 нче; 2015 ел, 27 июль, 546 нчы; 2016 ел, 2 ноябрь, 805 нче; 2017 ел, 22 апрель, 237 нче; 2018 ел, 29 гыйнвар, 49 нчы; 2018 ел, 12 июль, 564 нче; 2018 ел, 27 сентябрь, 867 нче, 2019 ел, 5 ноябрь, 1014 нче, 2021 ел, 6 август, 684 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамәгә теркәлә торган документлар составына, искәрмәләре белән 3  пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Авыл хуҗалыгы җитештерүен гамәлгә ашыру өчен яраклы булмаган җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән урман фонды җирләре категориясенә күчерүгә бәйле очракларда, шулай ук гамәлдәге ритуаль эшчәнлек объектлары урнашкан җир кишәрлекләрендә бер категориядән икенчесенә күчерүгә бәйле очракларда әлеге составның 6, 8 пунктларда, 9 пунктның икенче - бишенче абзацларында, шулай ук 12 пунктта күрсәтелгән документларны тапшыру таләп ителми.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин